ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«11» 03 2021 г. № 79

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны «Интернет» челтәрендә Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Коррупциягә каршы тору турында» гы 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм «Санлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы 2020 елның 31 июлендәге 259-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, «Санлы финанс активлары, санлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» гы Россия Федерациясе Президентының 778 – номерлы 10.12.2020 елгы Указы, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» гы 26.12.2020 N 97-ТРЗ номерлы ТР Законы нигезендә Балтач муниципаль районы башлыгы карар бирә:

1. Балтач муниципаль районы башлыгының 2015 елның 31 мартындагы 67 номерлы карары (18.08.2017 елдагы 137 номерлы редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең, аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Балтач муниципаль районының "Интернет" челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибе турындагы Нигезләмәнең 2 пунктындагы "г" пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

г) җир кишәрлеген, күчемсез мөлкәтнең башка объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлар, цифрлы финанс активлары, цифрлы

валюта сатып алу буенча алыш-бирешләрнең гомуми суммасы хезмәткәрнең (хезмәткәрнең) һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып киткән очракта, акча алу чыганаклары турында белешмәләр.

2. Әлеге карар кул куелган көннән үз көченә керә.

Балтач муниципаль
район башлыгы

Р. Р. Нотфуллин